СОВЕТ КУГУНУРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУНЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
30 сентября 2024 года

КАРАР
№ 102

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кунир авыл җирлеге Советының 2022 елның 01 июлендә кабул ителгән 55 нчы номерлы «Мөлкәткә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Куныр авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге Советының 01.07.2022 елның 01 июлендә кабул ителгән 55 нчы номерлы «Мөлкәткә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 нче пунктны түбәндәгечә үзгәртергә:

«Әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата (гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәклəрдән һәм сәүдә үзәкләреннән (комплекслардан) һәм алардагы урыннардан тыш), әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата – 2%;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктчасы өстәргә.:

«2025-2027 еллар чорына гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата – 1,2%;»;

1.3. 2.6 пунктчаны 3 пункт дип санарга, 3 пунктны 4 пункт дип санарга, 4 пунктны 5 пункт дип санарга, 5 пунктны 6 пункт дип санарга, 6 пунктны 7 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының http:pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Куныр авыл җирлеге башлыгы Р.О.Егоров